*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 40**

**1. Драма жанры турында исегезгә төшерегез. Аның үзенчәлекләрен барлап языгыз. Мисаллар китерегез. (5 балл)**

**Җавап:** ____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

**2. Рәсемгә игътибар итегез. Ул кайсы әсәр буенча эшләнгән? Әсәрнең исемен, авторын языгыз, әсәр геройларын атагыз. (5 балл)**



**Җавап:** ___________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

**3. Казан ханлыгы чоры әдәбияты кайсы гасырны үз эченә ала? Дөрес җавапны билгеләгез. (1 балл)**

а) XIII йөзнең урталарыннан алып XV гасырның ахырлары

ә) XV гасыр урталарыннан башлап XVI гасырлар

б) XV гасыр урталарыннан XVII гасыр урталарына кадәр

**Җавап:** ____________________________________________

**4. Алтын Урда чоры шагыйрен билгеләгез. (1 балл)**

а) Габделҗәббар Кандалый

ә) Муса Акъегетзадә

б) Сәйф Сараи

**Җавап:** __________________________________________


**5. Әсәрләрнең авторын, жанрын языгыз. (6 балл)**

а) «Милләткә» ____________________ __________________

ә) «Кыйссаи Йосыф» ___________________ _________________

б) «Дуслар җыелган җирдә» ___________________ __________________

**6. а) Портретка игътибар итегез. Биредә кем сурәтләнгән? (1 балл)**



**Җавап:** ____________________________________________

**б) Бу әдип турында өч фактны искә төшереп языгыз (6 балл)**

**Җавап:**

1) ______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

2) ______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

3) ______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

**7. Шигырьне укыгыз, анда бирелгән хис-кичерешләрне, аларның сәбәпләрен билгеләгез. (5 балл)**

**Сагыну**

Гөл чәчәкләрен өзәм мин,
Юлларыңа тезәм мин.
Бик сагындым, бәгърем,
Бик сагындым сине,
Әле дә ничек түзәм мин!

Таң атканда уянырмын,
Җилкәмә шәл салырмын.
Таң шикелле балкып
Тиздән кайтыр булсаң,
Каршы чыгып алырмын.

Җилбер, җилбер җил искәндә,
Үләнгә чык төшкәндә,
Бик күңелле булыр,

Бик кызыклы булыр,

Кайтсаң, сагынып көткәндә.

*Муса Җәлил*

**<u>Җавап:</u>**

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

**8. Сагынуга дәва юк, диләр. Сез килешәсезме? Әлеге фикерне дәвам итеп языгыз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытмагыз. (10 балл)**